СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

26 сентябрь, 1998 ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. № 110 (8267) Бәясе билгеләнгәнчә

***Татарстанда балаларның сәламәтлеген кайгырту елы бара***

## БЕЗНЕКЕЛӘР АЛЕКСЕЕВСКИДА БУЛДЫЛАР

*Бу атнада безнең район мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре ТР Мәгариф министрлыгы тарафыннан Алексеевскида үткәрелгән республика зона семинарында катнаштылар. Семинарның төп темасы "Мәгариф хезмәткәрләренең 1998 елның 7 августында булып узган республика конференциясе рекомендацияләрен үтәү яктылыгында ТР мәгариф системасының төп юнәлешләре" дип аталган иде. Ә нигездә ул укучыларның сәламәтлеген саклау мәсьәләләренә багышланды. Семинарда Нурлат, Спасс, Алексеевск, Әлки районы вәкилләре катнашты. Пленар утырышта һәм секцияләрдә эшләгәннән соң семинарда катнашучылар Алексеевскидагы 3нче урта мәктәп эшчәнлеге белән таныштылар.*

## Борчыган мәсьәләләр җитәрлек

### "Уңыш - 98" матбугат үзәге хәбәр итә

**Көннәрнең бозылып китүе берәү өчен дә көтелмәгән хәл булмады, билгеле. Шуны чамалап, алданрак аяк киенгән хуҗалыкларда туңга сөрү кебек эшне кара көзгә кадәр күп калдырмадылар. Нәтиҗәдә Муса Җәлил исемендәге, Синдряков исемендәге, "Сөлчә", "Дуслык", "Агрохимсервис" һәм сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыкларында сөреләсе мәйданнар санаулы гектарларда гына инде. Район буенча бу эш соңгы бер көндә 800 гектардан артыграк җирдә уздырылып, план үтәлеше 76 процент тәшкил итә. Ә менә "Чирмешән" агрофирмасында, Хафизов исемендәге, "Татарстан", "Алга", РСУ һәм шикәр заводы ярдәмче хуҗалыкларында бу яктан хәл һаман да мактанырлык түгел әле, туңга сөрү агрегатларының көнлек җитештерүчәнлеге дә әллә ни артмый.**

**Ә техника хәзер икенче уракны тизләтү өчен дә бик кирәк. Кичәге көнгә район буенча шикәр чөгендере 2362 гектардан казып алынды. Бер көндә казылган мәйдан 227 гектар булды. Бу эшне "Татарстан"да ашыктыра төшteләр, соңгы бер көндә "Өмет" агрофирмасында, "Рассвет", "Киекле", "Игенче", М.Җәлил исемендәге, "Алга" һәм кайбер башка хуҗалыкларда да эш темпы ярыйсы гына булды. Ә менә "Таң"да, "Чулпан"да, сөт - май комбинаты һәм шикәр заводы ярдәмче хуҗалыкларында чөгендер казу агрегатларының җитештерүчәнлеге элеккечә үк түбән.**

**Бер үк вакытта чималны заводка озату да көнүзәк бурыч булып кала килә. Бу урында кырда коелып яки казылмый калган барлык чөгендерне җыеп алуны оештыру зарурлыгына да басым ясарга туры килә. Соңгы бер көндә кагат кырларына мең ярым тоннадан артык чөгендер китерелде һәм шулай итеп барлыгы 11700 тонналап чимал заводта инде. 23 сентябрьдә иң күп чөгендерне "Кондырча" һәм Хафизов исемендәге хуҗалыклар китерде, беренчесенең барлык ташыган чөгендере 1400 тонналап булды. "Өмет" агрофирмасы 2800 тоннадан артыграк, "Киекле" һәм "Рассвет" 1800әр тонна чимал тапшырдылар. Ә менә "Татарстан"нан, "Чирмешән" агрофирмасыннан һәм сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыгыннан 23 сентябрьдә заводка бер генә йөк тә чимал килмәде. Район җитәкчелеге әзер чималны тизрәк ташыту өчен бар булган техниканы туплау чарасын күрә. Промышленность предприятиеләреннән генә дә көн саен алтмышлап машина тартыла. Маркетинг хезмәте департаменты, НГДУның технологик транспорт идарәсе, "Татнефть - Нурлатнефтеразведка", УМС кебек оешмалар бу эшкә җаваплылык белән карап, авыл эшчәннәренең хәленә керәләр. Транспортлары булган башка оешмалар, шул исәптән машина төзү заводы, 53 нче СМУ, Бентокам һәм башкалар да активлык күрсәтерләр дигән теләктә калабыз. Шикәр заводы үзе дә чөгендер игүче хуҗалыкларның барысын да тигез күрсә яхшырак булыр төсле. Районга "Елховнефть"тән дистәгә якын транспорт бирәмлеге тарту да юкка гына түгел бит.**

**Кукуруз уруны да сузуның мәгънәсе калмады кебек инде - аны быел бары силоска гына салып буласы көн кебек ачык. Әмма соңгы бер көндә урылган мәйдан йөз гектарга да тулмады. Темп бары Синдряков исемендәге хуҗалыкта гына ярыйсырак булды, ә калганнарында 5 - 10 гектар урудан ары китә алмадылар. Район буенча 74 мең тоннадан артыграк силос салынды. Сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыгында ул еллык ихтыяҗ кадәр, "Таң"да һәм Муса Җәлил исемендәге хуҗалыкта да бу төр план тулар төсле. Соңгысында бер шартлы терлеккә әзерләнгән азык бирәмлеге дә 26 центнердан артып китте инде. Ул яктан Синдряков исемендәге, "Үрнәк", "Алга", "Дуслык", "Төрнәс", "Заветы Ильича", сөт - май комбинаты, нефтебаза ярдәмче хуҗалыкларында да хәл чагыштырмача әйбәт кенә.**

**Тик әле киләсе ел иген уңышы язмышы да нык борчый. Сабан ашлыгы орлыгы салу эше һаман да канәгатьләнерлек түгел, уҗым культураларын тукландыру һәм эшкәртүне дә, көннәр болай торса, барлык мәйданнарда да уздырып булмау куркынычы бар.**



## ИКЕНЧЕ УРАК НИЧЕК БАРА?

***Район хуҗалыкларында 25 сентябрьгә шикәр чөгендере казу планының үтәлеше (процентларда)***

| | | | |
|---|---|---|---|
| "Игенче" | 80 | М.Җәлил исем. | 36 |
| "Рассвет" | 55 | "Чирмешән" агрофирмасы | 26 |
| "Татарстан" | 54 | Шикәр заводы ярд. хуҗ. | 26 |
| "Өмет" агрофирмасы | 46 | "Үрнәк" | 25 |
| "Кондырча" | 46 | "Чулпан" | 23 |
| "Киекле" | 42 | Хафизов исем. | 22 |
| Нефтебаза ярд. хуҗ. | 42 | Синдряков исем. | 20 |
| "Алга" | 41 | "Таң" | 19 |
| Сөт - май комб. ярд. хуҗ. | 40 | | |
| "Заветы Ильича" | 39 | **Район буенча** | **36** |

## ӨЛКӘННӘР КӨНЕНӘ ӘЗЕРЛӘНЕП

**1 октябрь - Өлкәннәр көне календарьдагы даталар арасында бигрәк тә аерымлысы: бу көнне без кадерле ветераннарыбызны хөрмәтләячәкбез, әбиләребез һәм бабаларыбызның, әти - әниләребезнең яшьлекләре узган елларга кабат - кабат әйләнеп кайтачакбыз. Һәм бу бәйрәм бернигә дә карамыйча билгеләп үтелергә хаклы. Республика Министрлар Кабинеты да шундый карарга килде, ул хакта шәһәр һәм район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин да халык депутатларының берләштерелгән Советы сессиясендә ачык иттереп әйтте.**

**Ул көнне, аерым алганда, предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр, үзләренең ветераннарын туган коллективларына чакырып, чәй табыны артына җыячаклар, концертлар оештырып та күңелләрен күрәчәкләр, мөмкинлектән чыгып азык - төлек пакетлары да өләшәчәкләр. Һәркайда пенсионерларга мөмкинлектән чыгып төрлечә: утын - күмер кайтарту, йортларын төзәттерү, җыештыру һәм башка эшләрдә ярдәм ителәчәк. Соңгысына мәктәп балаларын тарту да мәслихәт (тимурчылык хәрәкәте бөтенләй үк сүрелмәгән бит әле). Ә инде шәһәрдә һәм авылларда ул көнне конкрет нинәр эшләнәчәге турында газетабызның алдагы санында хәбәр итәчәкбез.**

## РУХИ ЧИШМӘЛӘРЕБЕЗ НИ ХӘЛДӘ?

***Соңгы елларда район мәдәният бүлегендә авыл мәдәни - агарту учреждениеләрендә эшләүче кадрларның хезмәтен елга бер тапкыр тикшереп, бәяләп, йомгак ясау һәм алдагы көнгә бурычларны да шул тикшерү нәтиҗәләреннән чыгып билгеләү зарури бер чарага әверелде.***

Бүлек методистлары һәм китапханә системасы хезмәткәрләре авыл мәдәният йортлары һәм клублары, китапханәләрнең һәркайсында булып, эшнең торышы, кадрларның хәзерлек дәрәҗәсе белән таныштылар. Күп кенә мәдәни учреждениеләрнең җылыту системасы газ белән ягуга күчерелгән һәм кайберләре киләчәктә күчерүгә хәзерлек алып баралар. Биналарга капиталь һәм косметик ремонт үткәрелгән. Бу эшләр күпчелек очракта җирле үзидарә органнары ярдәме белән башкарылган.

Әмма һәрбер клуб яки мәдәният йорты турында болай дип әйтеп булмый әле. Әйтик, Иске Чаллы (директоры В.В. Итрин), Кизләү (Ф.Ю. Вафина), Кормыш (Н.Н. Җәлалова) авыл мәдәният йортларының эшен башкаларга үрнәк итеп күрсәтәбез икән, бу аларның җирле үзидарә органнары белән кулга - кул тотынып эшләве нәтиҗәсе дә бит. Ә менә Сәләнгештә мәдәни - агарту учагының хәле җирле үзидарәне бер тамчы да борчымый. Югыйсә, тату хезмәттәшлек авыл җирендә әхлакый тәртипне саклауга, яшьләр тормышын кызыклырак итүгә һәм шуның белән тәрбияви максатка хезмәт итәр иде.

Авыл мәдәният учакларының махсус белгечләр белән тәэмин ителеше дә мактанырлык түгел. Райондагы 53 шундый учреждениедә эшләүчеләрнең 3се генә һөнәре буенча югары белемгә ия. Барлык белгечләрнең яртысы гына махсус урта белемле. (Читтән торып укучылар да дүртәү генә.) Калганнары исә урта белемле кешеләр. Шуңа күрә дә кадрлар белән эшләүдә контракт системасы булу белемгә ихтыяҗлык мәсьәләсен хәл итүгә этәргеч бирә. Яшьләрнең уку йортларына керүе, ә инде тиешле яшьтән узганнарның Казан мәдәният академиясе оештырган белем күтәрү курсларында хәзерлек алуы җитди таләп буларак куела.

Ә инде китапханәләргә килсәк, алар белгечләр белән күбрәк тәэмин ителгәннәр. Китапханәләр эшчәнлегендә мөдирләрнең хәзерлеге, интеллектуаль дәрәҗәсе зур роль уйный. Әйтик, Колбай Мораса авылы китапханәсендә (мөдире Т.И.Мингалиева) булган кеше мондагы иҗади рухка игътибар итми калмый. Вакытлы матбугатның бүгенге гаҗәп киңкырлы, бай тематикасы тынгысыз җанлы китапханәчегә никадәр "азык" бирә. Җирле тарихка, авыл тормышына кагылышлы күп төрле эшләнмәләр һәм шуларга нигезләнеп үткәрелгән тәрбияви чаралар һәммәсе дә китапханә тормышын күпкә баета һәм җанлырак итә. Кычытканлы (мөдире Д.Р.Мансурова), Югары Нурлат (М.З. Әһлиуллина) авылы китапханәләре дә активлыклары белән мактауга лаек.

Дөрес, китапханәләр дә күп очракта авыл мәдәният йортлары һәм клублар кебек үк "үги кыз" хәлендә. Ремонт үткәрү, яңа китаплар кайтарту кебек мәшәкатьләр күбесе өчен баш җитмәслек хыял гына. Татар авылларындагы китапханәләргә соңгы 10 елда татарча басмаларның бер дә кайтмавы шулай ук бик борчый. Һәм монда теләсә нинди аклану да урынсыз. Нинди генә кытлык, хәерчелек хөкем сөргән заманнарда да безнең халык китаптан, җыр - биюдән аерылмаган, киресенчә, үзенең рухын шулар ярдәмендә саклаган, яңартып торган, ләбаса.

**Г.ӘҺЛИУЛЛИНА,**
**район мәдәният бүлеге методисты.**

## Урман җыры - сезнең язмыш


# ҮЗ УРЫНЫНДАГЫ КЕШЕ

***Быелгы җәй Тумба урманчылыгы башлыгы Анатолий Николаевич Семенов өчен аеруча тынгысыз булды: шырпы дөртләп кабынырдай кызу көннәр иде шул, янгын казасын көт тә тор! Янгын ул - урман өчен иң явыз афәт. Ә аның сәбәпчесе - күп вакытта кеше. Сүндереп бетерелмәгән җылы учакның да хуҗасы кеше бит. Битарафлык белән ташланган төпчек ияс̃е дә ул. 1972 елның быелгыдай ми көйдергеч эссе җәендә, июль аенда Тумбада һәм башка урманчылыкларда тоташ зәңгәр төтенгә уралып янган урманнарны урманчы әле дә яхшы хәтерли. Меңнәрчә гектарлар көлгә әйләнде ул чакта. Ә бит яшь үсентеләр зур агачка әверелгәнче күпме гомер үтә! Өлгереп җитү өчен каенга 50 ел, ә наратка бөтенләй 80 - 100 ел кирәк. Тулаем урман хуҗалыгындагы кебек үк бу урманчылыкта да әлеге афәттән котылып калдылар. Аншлаглар куйдылар. Юл буйларында тоткарлау полосалары өйделәр. Урман каравылчылары тәүлек әйләнәсенә кизү тордылар. Урман кишәрлекләренә туктаусыз күзәтчелек иттеләр. Кешеләр белән әңгәмәләр үткәрделәр. Май бәйрәмнәрендә урман культуралары утырту белән шөгыльләнделәр. Ә ял көннәрендә Чирмешән буйлап ял итүчеләрнең каеклары агылды: урманлы гүзәл табигать кешеләрне үзенә тарта иде. Анатолий Николаевич берсенә дә вакытын кызганмады: учакларның соңгы күмере янып беткәнче күзәтте, учак әйләнәсенә канау казып чыкты, төнгелеккә кизүләр билгеләде. Һәм бу бер генә очрак түгел бит.***

Нәрсә дип ул гомерен урман белән бәйләгән соң? Уйлап карасаң, урман бу якларда беренче туендыручы бит. Сигезьеллык мәктәпне тәмамлагач, такта ярдыручы ярдәмчесе, тракторчы булып эшләде. Армиядән соң янәдән тракторга утырды. Шул вакытта урман каравылчысы Кучкин карт (заманы өчен тормышны күргән, алтын бәясенә торган белгеч иде): "Урман каравылчысы булып урнаш син. Кулыңнан киләчәк. Мин кешене таный беләм",- дип киңәш биргән иде. Чынлап та шулай булды. Эшләде һәм бер үк вакытта читтән торып урманчылык техникумында укыды. Урман каравылчысы, урманчы ярдәмчесе, урман мастеры, урман пункты башлыгы - аның хезмәт кенәгәсендә менә шулар язылган. Былтыр май аенда Тумба урман пунктын һәм урманчылыкны бер бөтен итеп берләштерделәр. Бүгенге көндә Анатолий Николаевич шушы хуҗалыкка җитәкчелек итә.

Аның Октябрь урман хуҗалыгына килүенә быел декабрьдә 17 ел тула. "10 ел. Дәүләт урман сакчылыгында озак еллар намуслы хезмәте өчен" дигән билге белән бүләкләнгән булган. Мондый бәя һәр кешегә дә эләкми. Урман язмышы турында кайгырту белән сугарылган мәшәкатьле еллар. Ә аларның кайчан мәшәкатьсез булганы бар соң? Кичәме, әллә бүгенме? Проблемалар җитәрлек, ләкин Семеновның сүзе эштән аерылмый. Коллективның бурычларын ул бик ачык күзаллый. Корылыктан һәлак булыр чиккә җиткән урман культураларын тергезү, пошилар таптаган үсентеләрне коткару һ.б. Эре үсентеләр үстерү куелган хезмәтне һәм вакытны, тотылган чыгымнарны башкалардан тизрәк аклый. Эш урыннарын саклау, хезмәт программасын үтәү, урманга зыян китермичә генә кулланучының барлык ихтыяҗларын канәгатьләндерү, урманның киләчәге турында кайгырту - бүгенгенең иң мөһим бурычлары шулар.

Урманчы үзенең эшенә кагылышлы барлык саннарны да хәтердән әйтте. 15 гектар мәйданда урман саклау полосалары булачак (монда нарат үстерү күздә тотыла). 28 гектар - урман фондына. Питомниктагы 20 сутыйда үсенте орлыклары чәчелгән. Агач әзерләү 17 процентка арткан. Сатуда гел булып тора торган рәшәткәлек һәм башка материаллар буенча еллык планның (3493 кубометр) гыйнвар - август айларында 3014 кубометры башкарылган. Монда бура да бурыйлар - заказлар гына күбрәк булсын. Гомумән, җитештереп сату мәсьәләсенә тулаем урман хуҗалыгындагы кебек үк Тумба урманчылыгында да бик җитди карыйлар, чөнки ул "саф акча" белән турыдан - туры бәйләнгән. Мондагы җитәкчелек үзенең коллективына һәрьяклап ярдәм күрсәтергә тырыша. Хезмәт хакы хисабына капчыгын 95 сумнан 1нче сортлы он кайтардылар - кайдадыр ул тагын да кыйммәтрәк. Дуңгыз итенең килограммын 11 сумнан "Нива" авыл хуҗалыгы кооперативыннан китерделәр. Атланмай яки үзебездә җитештерелгән токмач шулай ук кирәкле нәрсәләр. Печән, утын, шифер тараттылар.



Н.АЗИЗОВ ФОТОСЫ.

Урманчы Семенов эшчеләрнең торак шартлары турында кайгыртуны аерым игътибарда тота. Бүгенге көндә Тумбада 4 гаилә йорт төзи. Болар - шофер, урман каравылчысы... Мастер да материаллар хәзерләгән. Төзү өчен кирәкле агачны үз эшчеләренә түләүсез бирәләр һәм транспорт белән дә булышалар.

- Кешеләрнең төзегәнен яратам, төзесеннәр дип телим. Чөнки бу җирдә беребез дә мәңгелек түгел, ә урманга эшче куллар кирәк. Үз куллары белән йорт салган кеше моннан китми ул. Тир түгеп эшләгәнеңне чит кешегә ташлап китмисең,- ди Анатолий Николаевич.

Теләүчеләр әле тагын булыр. Урманчы аларны да ярдәменнән ташламас.

Коллективы хакында да яратып сөйли ул. Юкка - барга мактамый. Ләкин карусыз, эш сөючән шофер егетне - Радик Моратовны телгә алды. Армиядән соң аңа ГАЗ - 53 машинасын биргәннәр, соңрак урман ташу өчен яңа машина кайтарганнар. Егет берсендә дә сынатмаган. Тракторчы Николай Антонов үзенең тәҗрибәсе һәм башкару төгәллеге белән аерыла. Мастер Андрей Андреев эшне оештыручы буларак тәртип урнаштыра белә. Алар гаиләдә 11 бала үсәләр, ә ул, иң кечесе буларак, элеккеге гаилә кануннары буенча авылда кала. Үз гаиләсен кора, өй төзи - урманчылыкта эшләргә дә җирле кеше кирәк бит, аны вакытлы кешеләргә ташлап булмый...

Булмый, моны кичермәсләр. Шулай дип уйлый Анатолий Николаевич. Бәлки шуңа күрәдер дә, 7 яшьлек төпчеге - Андрейның урман каравылчысы булырга теләвен хуплыйдыр. Улын үзе белән ауга, балыкка, гөмбәгә алып баруы, кайчак болай гына - наратлыкта бергә йөрергә генә дә чакыруы - сабый күңелендәге кызыксынуның очкынын саклап калырга теләведер, мөгаен.

... Безнең Анатолий Николаевич Семенов белән беренче генә очрашуыбыз түгел. Бу юлы да күп нәрсәләр хакында сөйләштек. Чирмешән буендагы, күрше Иске Тумба авылыннан 5 - 6 километрда урнашкан питомникка да барып килдек, сугышка кадәр кара - көрән төлкеләр үрчетелгән җәнлекләр фермасы урынын да карадык. Анатолий Николаевич белән сөйләшү үзе бер җан рәхәте. Ул ачык, аралашучан, уйланучан, икътисадый үзгәрешләрнең барлык нечкәлекләрен тоемлап бәяләүче кеше. Телевизордан матур тавыш белән сөйләнүче ялганнарга ул ышанмый. Үз - үзеңә, коллектив көченә ышанырга, авырлыклар алдында югалып калмаска, үзеңнең кече Ватаның булган урманны сакларга кирәк дип саный ул. Чөнки урман исән булса - кеше дә яши.

**Т.НАЗАРОВА.**

# СӨТНЕҢ СЫЙФАТЛЫСЫ ГЫНА АКЧАЛЫ

**Саннарның беренче баганасы - 8 айда дәүләткә сатылган сөтнең майлылыгы, икенчесе - 1 сорт белән сатылган сөт (процентларда), өченчесе - майлылык буенча исәпләгәндә өстәп яки киметеп язылган акча, дүртенчесе - 1 сорттан түбән сөт сатудан, бишенчесе - сөтне суытмыйча сатудан, алтынчысы - барлык югалган акча (сумнарда).**

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| "Киекле" | 3,68 | 85 | + 34300 | - 24710 | 119 400 | 109810 |
| Мичурин исем. | 3,61 | 85 | + 6370 | - 30300 | 113200 | 137130 |
| Хафизов исем. | 3,68 | 95 | + 15974 | - 8982 | 55800 | 48808 |
| М.Җәлил исем. | 3,67 | 81 | + 5390 | - 5490 | 16100 | 16200 |
| "Родина" | 3,56 | 90 | + 6076 | - 6237 | 18800 | 18961 |
| "Игенче" | 3,58 | 95 | + 2254 | - 3303 | 32200 | 33249 |
| "Заветы Ильича" | 3,57 | 78 | + 4606 | - 12477 | 37600 | 45471 |
| "Алга" | 3,44 | 74 | + 29204 | - 42264 | 39500 | 52560 |
| "Комбайн" | 3,61 | 95 | + 1862 | - 2715 | 21200 | 22053 |
| "Татарстан" | 3,72 | 88 | + 35966 | - 19242 | 63900 | 47176 |
| "Чулпан" | 3,66 | 85 | + 5586 | - 38967 | 22300 | 55681 |
| "Таң" | 3,66 | 74 | + 4704 | - 10356 | 24500 | 30152 |
| "Үрнәк" | 3,64 | 82 | + 5390 | - 14568 | 39100 | 46900 |
| "Кондырча" | 3,68 | 73 | + 14994 | - 16344 | 54900 | 56250 |
| Кузнецов исем. | 3,49 | 91 | - 31850 | - 11676 | 69400 | 112926 |
| "Заря" | 3,56 | 86 | - 4998 | - 6348 | 18700 | 30046 |
| "Чирмешән" | 3,62 | 78 | + 5684 | - 23040 | 52800 | 70156 |
| Синдряков исем. | 3,64 | 95 | + 13230 | - 5508 | 66600 | 58878 |
| "Рассвет" | 3,74 | 75 | + 32340 | - 22098 | 62200 | 51958 |
| Нефтебаза ярд. хуҗ. | 3,66 | 59 | + 3822 | - 16071 | 17500 | 29749 |
| Шикәр заводы ярд. хуҗ. | 3,60 | 96 | - | - 3090 | 12590 | 15680 |
| "Агрохимсервис" ярд. хуҗ. | 3,51 | 63 | - 6566 | - 11700 | 19300 | 37566 |
| Сөт - май комб. ярд. хуҗ. | 3,60 | 92 | - | - 1710 | 20700 | 22410 |
| "Төрнәс" | 3,69 | 86 | + 18522 | - 15000 | 48500 | 44978 |
| РСУ ярд. хуҗ. | 3,76 | 72 | + 19012 | - 14700 | 16000 | 11688 |
| "Сөлчә" | 3,60 | 80 | + 588 | - 13770 | 27700 | 40882 |
| "Дуслык" | 3,66 | 90,3 | + 7350 | - 1170 | 34900 | 28720 |
| **Район буенча** | **3,63** | **85** | **+ 146804** | **- 358230** | **1141400** | **1352826** |

Мәгълүматлардан күренгәнчә, сигез айда хуҗалыклар сөт җитештереп сатуда шактый зур гына зыянга эшләделәр. Ә бит ныклап исәпләп карасаң, дәүләткә сатылган продукциянең сыйфаты турында тиешенчә кайгыртканда ул югалтулар азрак булырга яки бөтенләй дә булмаска мөмкин икәнлеге дә ачык күренә. Бер генә мисал. РСУ ярдәмче хуҗалыгы, мәсәлән, базис майлылыгыннан куерак сөт өчен 19 мең сумнан күбрәк өстәмә акча алырга тиеш булса да, шуның 16 меңен сөтне суытмыйча китергәнлек аркасында югалткан, шуңа тагын I сорттан түбән сөт саткан өчен югалтуын да китереп кушкач, 12 меңгә якын акчасы җилгә очкан булып чыга. "Родина", "Кондырча", "Игенче", "Алга", "Таң", "Үрнәк", "Чирмешән" һәм башка хуҗалыкларның майлылык өчен аласы меңнәрен түбән сортлылыктагы, ә Муса Җәлил исемендәге хуҗалыкныкын I сорттан түбән киткән сөтләре "йоткан".

Майлылык дигәннән, быел сигез айда кайбер хуҗалыкларның майлылык мәсьәләсендә дә былтыргыдан чигенеш ясауларын билгеләп үтми мөмкин түгел. "Киекле","Дуслык", М.Җәлил исемендәге, Синдряков исемендәге, "Татарстан", "Чулпан", РСУ һәм нефтебаза ярдәмче хуҗалыклары аны 0,05 - 0,08 процентка арттырган вакытта, Кузнецов исемендәге, "Алга", "Заветы Ильича", "Игенче" хуҗалыклары шул кадәргә үк киметтеләр, сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыгында да ул күрсәткечнең 0,11 процентка кимеп, базис майлылыгында гына калуын хуплап булмый. Әнә бит, Кузнецов исемендәге хуҗалык сөтнең майлылыгы түбән булудан гына да 32 мең сум чамасы акча югалткан инде быел.

Беренче сорт белән сатылган сөтнең чагыштырмача күләмен РСУ ярдәмче хуҗалыгы, "Кондырча", "Чирмешән" һәм "Рассвет" быел сигез айда узган елгыдан 20 -24 процентка, ә нефтебаза ярдәмче хуҗалыгы өчтән бер өлешкә диярлек киметтеләр. Ә бит "Дуслык", "Игенче", "Татарстан"да ул күрсәткечне былтыргы дәрәҗәдә саклап кала алдылар, ә шикәр заводы ярдәмче хуҗалыгы, "Комбайн", "Киекле", "Төрнәс" әле 5 - 11 процентка арттыруга да ирештеләр.

Кыскасы, продукцияне җитештерүгә тотыла торган чыгымнарның һәм хезмәтнең әрәмгә китмәвенә, ә киресенчә,хуҗалыкка өстәмә акча китерерлек булуына ирешү өчен ул продукцияне ничек тә отышлырак иттереп сату турында һәрдаим кайгыртырга кирәк. Ә терлекчелек продукциясенә бәяләр әлегә көйләүле булганда, товарыңнан күбрәк файда күрү юлы бер генә - аны ничек тә сыйфатлырак иттереп тапшыру.

**Укучыларыбызны кызыксындырган сорауларга Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе җитәкчесе Рәфгать МИНХАНОВ, аның урынбасары Ислам ГАЛЛӘМОВ, Казан шәһәре эчке эшләр идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге инспекциясе бүлеге башлыгы урынбасары Нариман ШӘРӘФИЕВ җавап бирә.**




***- Техника белән идарә итү таныклыгымны һәм техпаспортымны югалттым. Бу документларны яңадан ничек алып була?***

- Мондый очракта Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт автоинспекциясе идарәсенең (ЮХИДИИ) имтихан бүлегенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бу эшләр, әлбәттә, яшәгән урыныгызда башкарылырга тиеш. Сездән - гариза, шоферлык курсларын үтүегез, дәүләт файдасына тиешле түләүләрне кертүегез, автомобиль йөртергә яраклы булуыгыз турында белешмәләр, яшәү урыныгызда теркәлгән паспортыгыз таләп ителә.

***- Дәүләт автоинспекторлары шәхси автомобильләрендә йөргәндә башка машиналарны туктатып, документларын тикшерергә хокуклымы?***

- Юк, шәхси машиналарында юлларда патруль хезмәтендә булу катгый тыела.

***- "Тойота" машинасы алдым. Арткы пыяласы төсле, шунлыктан машинаны теркәтә алмыйбыз.***

- Мондый транспортны куллану ГОСТ-5727-88 таләбе буенча тыела. Автомобильнең алгы пыяласы яктылыкны - 75, арткысы - 70 процент үткәрергә тиеш.

***- Автоинспектор буларак шуны ишеттем: яңа закон нигезендә автоинспекциядә хезмәт урыннарын кыскартулар көтелә, имеш?***

- РФ Президенты Б.Ельцин фәрманы буенча (15.06.98 ел) Татарстан Республикасында өстәмә 3500 хезмәткәр алырга кирәк булачак. Шунлыктан, уйлавыбызча, штатлар кыскарту түгел, яңа әйбәт кадрлар туплый башлау көтелә.

***- Испектор утырган автоинспекция машинасы агачлыкка яшерелгән. Юл хәрәкәтендәге автомобильләрне гадәти киемдәге кеше туктата да инспектор янына озата. Бу дөрес эшме?***

- Россия Эчке эшләр министрлыгының 1994 елның 10 гыйнварында чыгарылган 6нчы санлы таләбе буенча дәүләт автоинспекциясе хезмәтен ачыктан - ачыкта, яшерен дә үткәрергә хокуклы. Татарстанда соңгы вакытта, нигездә, ачыктан - ачык кизү торалар.

Транспортны ЮХИДИИ стажеры да туктатырга хаклы. Стажерның беләгендә кызыл тасма, кулында жезл (аклы - каралы таяк) һәм сызгы булуы шарт.

Россия Эчке эшләр министрының 1998 елның 1 июнендә кабул иткән 329нчы боерыгы буенча автоинспектор машинаны туктаткач, юл хәрәкәтендә катнашучы белән ачык итеп исәнләшергә, үзенең фамилиясен, дәрәҗәсен әйтергә, автомобильне ни өчен туктатканлыгын аңлатырга тиеш.

***- Милициядә теркәлмәгән паспорт буенча техника белән идарә итү хокукы таныклыгы ала аламмы?***

- Юк, теркәлмәгән паспорт белән хокук таныклыгы алып булмый. Имтихан кабул итү, документлар бирү граждannарның торган урыныннан чыгып эшләнелә, яисә инде алты ай дәвамында вакытлы тору урыны булу шарт. Ләкин паспорт барыбер теркәлергә тиеш.

***- Баш инспектор район бүлекчәләрендә еш буламы? Автоинспекциягә эшкә алганда нинди таләпләр куела?***

- ЮХИДИИ җитәкчесе үзенә буйсынган бүлекчәләрдә даими булып тора. Автоинспекторлар белән киңәшмәләр үткәрә, аларның өйрәнүләрендә катнаша. Хезмәткә алганда кадрларның белеме, физик һәм психологик әзерлеге тикшерелә. Болардан тыш автоинспекторларның елына ике тапкыр һөнәр листоклары, төрле яктан әзерлекләре тикшерелә. Тиешле таләпләргә җавап бирмәгән хезмәткәрләр эшләреннән азат ителәләр.

***- Кизү торучы инспекторларыгызны тикшерәсезме? Алар арасында тәмәке тартып, йә көнбагыш чиртеп, йә кулларын кесәләренә тыгып торучылары да очрый.***

- Тикшерәбез. Әгәр тәртип бозучы фаш ителсә, аңа карата тиешле чара күрәбез. Үзләрен әдәпсез тоткан автоинспекторларга юлыксагыз, безгә 41-30-82 телефоны аша хәбәр итегез.

***- Штрафны "тере" акча белән түләмәү мәсьәләсе кайчан тормышка ашар?***

- Бу мәсьәлә Россиянең ЮХИДИИ баш идарәсе тарафыннан өйрәнелә. 1999 елга кадәр, мөгаен, карар кабул ителәр.

***- Минем әлегә техника белән идарә итү таныклыгым юк. Шулай да үз машинамны йөртергә өйрәнәм. Ирем янәшәдә булганда мин руль артына утыра аламмы?***

- Машинаны ябык автодромнарда, кешегә комачауламый, хәвеф - хәтәр тудырмый торган урыннарда йөртергә өйрәнәләр. Өйрәнчек юлларга машинаны азмы - күпме йөртергә өйрәнгәннән соң гына чыгарга хокуклы. Өйрәтүчедә өйрәтүче оста таныклыгы яки өч елдан да ким булмаган стажлы шофер таныклыгы булырга тиеш. Өйрәнүчеләрнең машиналарында "У" рәвешендәге махсус тамга торуы да зарури.

***- Автомобильләргә техник карау кайсы вакытларда үткәрелә? Кулдан язылган ышаныч таныклыгы буенча машина йөртергә ярыймы?***

- Автомототранспортка һәм тагылма арбаларга техник карау 1 гыйнвардан 31 июльгә кадәр үткәрелә. Кешеләрне даими рәвештә ташучы, сигез һәм аннан да артык пассажир алучы автобус тибындагы машиналарны икенче әйләнеш карау 1 сентябрьдән 31 октябрьгә кадәр үткәрелә. 5 елдан артык файдаланылган шәхси транспорт ел саен тикшерелә. 5 елга кадәрге техника ике елга бер мәртәбә тикшерелә: так елда чыкканы - так елда, җөп елда чыкканы - җөп елда. Эшмәкәрләрнең автотранспорты ел саен тикшерелә. Кеше ташучы автобуслар елына ике тапкыр техник карау узалар.

Кулдан язылган ышаныч таныклыгы буенча машина йөртүне Граждaнлык кодексы рөхсәт итә.

***- Татарстанда бирелгән "Саф һава" талоны Мәскәүгә ярамый. Моны ничек аңларга?***

- Татарстан Министрлар Кабинетының 1997 елның 25 мартында кабул иткән 257 нче карары нигезендә Татарстандагы автотранспортның газлылык микъдары тикшерелә һәм махсус талон бирелә. Мәскәүдә ул талон гамәлдә түгел.

***- 1998 елда яңа автомобиль сатып алдым. Нигә әле ул диагностика үтәргә тиеш?***

- "Юл хәрәкәте иминлеге" һәм "Россия Федерациясендә техник карау һәм машиналарга тагылма арбаларның техник халәтен тикшерү" турындагы федераль законнар нигезендә республикада булган бар төр транспорт тикшерелә, шул исәптән яңа транспорт та.

***- Автоинспекторлар түгел, ә милиция хезмәткәрләре төнлә белән ишегалдыбызда туктатып документларымны тикшерде. Моңа аларның хакы бармы?***

- Россия Эчке эшләр министрының "Россия Эчке эшләр министрлыгының эшен яңадан кору турында" 1998 елның 1 июнендә кабул иткән боерыгы нигезендә милиция машиналарны түбәндәге сәбәпләр булганда туктатырга һәм тикшерергә хаклы. Болар: юл һәм административ кагыйдәләрне бозганда, җинаять эшләгәндә, автотранспорт милиция тарафыннан эзләүдә булганда, машина иясеннән юлда булган хәлләр турында, административ хокук бозулар хакында сорау алу ихтыяҗы туганда, хәрәкәт ешлыгын киметү максатында, юл хәрәкәтендә катнашучы икенче берәүләргә ярдәм, шулай ук милициянең хәлиткеч эшләрен башкару өчен, документларны тикшерү нәүбәтендә.

Гомумән, закон буенча автотранспортны автоинспектор һәм участок инспекторы гына туктата ала. Милиция исә, машина урланган дип уйласа, машинада урланган товар бар дип, йә автомобильдә җинаятьчеләр утыра дип шикләнсә, туктата ала.

***- Минем, спиртлы эчемлек кулланып руль артына утырганым өчен, өч елга техника белән идарә итү хокукымны алдылар. Яңадан имтихан тотарга тиешменме, юкмы?***

- Бу төрдәге җәза вакыты 12 айга гына калдырылды. Ләкин кабаттан имтихан тапшыру таләбе саклана.

*("Шәһри Казан"нан бераз кыскартулар белән).*

# БЕЛДЕРҮЛӘР

## САТАБЫЗ

**Туй күлмәге.**
Тел.: 5-22-92.

***

**"Сәламәтлек" (үзәк шифаханә) ширкәтендә дача.**
Тел.: 5-12-53, кичке 8 дән соң.

***

**Чапаев урамында 19 нчы йорт (табигый газ кергән, суы бар), вариантлар мөмкин.**
Кичке 5тән соң мөрәҗәгать итәргә.

***

**1997нче елгы ВАЗ-21099.** Тел.: 5-14-23.

***

**5 х 5ле бура, кыйммәт түгел.** Мамыкта Федоровка мөрәҗәгать итәргә, тел.: 4-12-13.

## АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Өч бүлмәле йортны - Яр Чаллыда яки Түбән Камада 2 бүлмәле фатирга. Беренче һәм соңгы катлардан тәкъдим итмәскә.**
Нурлатта адрес: Тельман ур., 34"а" (элеккеге кинопрокат янында).

## ТӨРЛЕСЕННӘН

**Төзүчеләр турында бушлай мәгълүмат бирәм. Сыйфатлы итеп йортлар, гаражлар, янкормалар салалар, эретеп ябыштыру эшләре башкаралар.**
Тел.: 5-16-25, Нәҗип.

***

**Кутузов урамындагы 12а шәхси йортка торырга кертәбез.**
Лермонтов ур., 31 адресы буенча мөрәҗәгать итәргә.

***

**ОСТОның Нурлат район Советы "В","ВС", "ДЕ" категорияләренә укырга җыя.**
Тел.: 2-25-80.

***30 САНТИМЕТРДАН ОЗЫНРАК БУЛГАН ЧӘЧЛӘР САТЫП АЛЫНА. БАРЫ БЕР ГЕНӘ КӨН.***

***Сезне 2 октябрьдә иртәнге 9дан кичке 5кә кадәр Мәктәп урамында, "Көнкүреш йорты"ның хатын - кызлар залында көтәләр.***

***Килми калмагыз, күрми калмагыз!***

**ВИТАЛИЙ АГАПОВ - НУРЛАТ СӘХНӘСЕНДӘ**

***30 сентябрьдә Нурлат район мәдәният йортында танылган көйләр остасы, җырчы Виталий Агапов һәм аның концерт төркеменең чыгышы була.***



Концерт кичке сәгать җидедә башлана, билет бәясе - 15 сум.

# Булмас димә, дөнья бу!

## ЙӨГЕРӘ-ЙӨГЕРӘ ИЛЛӘР АША ...

Лондоннан дөнья тирәли сәяхәткә чыккан йөгерешче Роберт Гарсайдер сәгатенә уртача 10 чакрым йөгереп үтә. Швейцариядән соң ул кыю спортчы, 50 ил аша йөгереп, якынча 53 мең чакрым юл узачак. Гарсайдер сәяхәте 1999 елда Лондонда тәмамланачак.

## ВЕЛОСИПЕДТА - ДӨНЬЯ ТИРӘЛИ

1992 елның 21 апрелендә Һиндстанның Калькутта шәһәреннән юлга чыккан һинд велосипедчысы Рам Чандра дөнья тирәли сәяхәтенең 2000 елда тәмамланачагын белдерде.

## БАШВАТКЫЧ ЯЗМА

КАР. Африканың Сахара чүлендә яшәүче туарег халкының алфавитындагы хәрефләр гаҗәеп үзенчәлеккә ия. Бар хикмәт шунда: аларны теләсә кайсы юнәлештә - уңнан сулга яки киресенчә, я булмаса, астан - өскә, өстән - аска таба язарга була.

**("Юлдаш"тан).**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

Учредительләр: Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.
Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2361 данә. 4004